ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.06.2025 ел Баулы шәһәре №75

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 7 ноябрендәге 156 номерлы «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 27 маендагы 362 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 16 сентябрендәге 789 номерлы карары белән расланган, 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативына үзгәреш кертү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 7 ноябрендәге 156 номерлы «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативын әлеге карар белән расланган яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 апреленнән барлыкка килгән

хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 7 ноябрендәге
156 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН
(Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 17 июнендәге
75 номерлы карары
редакциясендә)

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү
бәясе нормативлары

| Норматив атамасы | Укыту чорында бер көнгә бер укучыга бәя нормативлары, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны тукландыру белән тәэмин итү хакының нормативлары | 10,3 | 10,0 | 10,4 |